ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
**05.09.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**БОЕРЫК**
**№ 03-05-995**

Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе төзү турында

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2016 елның 28 гыйнварындагы ПР-19 номерлы Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр эшчәнлеген контрольдә тотуның нәтиҗәлелеген арттыру буенча йөкләмәләр исемлегенең 5.1 пункты, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә

1.Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре эшчәнлегенең төп күрсәткечләре начарлану тенденциясенә ия булган финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе төзергә.

2. Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе составын әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча расларга.

3. Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе нигезләмәсен әлеге боерыкка 2 нче кушымтада каралганча расларга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018елның 05 сентябрендәге
03-05-995 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Сапожников Д.А. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **- председатель;** |
| Гарипов А.Ш. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - **рәис урынбасары;** |
| Сибгатуллина Л.Н. | «ЗМР мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ мөлкәт белән идарә итү бүлеге башлыгы - **секретарь**. |

**Күзәтчелек советы әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Стерякова А. С. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый фаразлау бүлеге башлыгы; |
| Гусев Н.В. | «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе; |
| Дёгтева О.П. | «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесе; |
| Благовещенский И.В. | « Зеленодольск муниципаль районының «ЗМР ТКХ департаменты» МБУ җитәкчесе урынбасары. |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 05 сентябрендәге
03-05-995 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Зеленодольск шәһәре» һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлекләре милкендәге унитар предприятиеләре эшчәнлегенең төп күрсәткечләре начарлану тенденциясенә ия булган финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау буенча баланс комиссиясе (алга таба - Комиссия) хокукларын, тәртибен, составын, функцияләрен, эш тәртибен билгели.

1.2. Комиссия муниципаль унитар предприятие эшчәнлегенә карата нәтиҗәле идарәчел карарлар кабул итү максатларында, тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр әзерләүгә юнәлдерелгән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.3. Комиссия Комиссия рәисеннән, урынбасарыннан, секретареннән һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

1.4. Комиссия утырышында эшчәнлекләренең төп күрсәткечләре начарлануга тенденциясе булган предприятие директоры һәм бухгалтеры булуы мәҗбүри.

1.5. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә җитәкчелек итә.

## 2. Комиссия функцияләре

2.1. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

- эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру һәм финанс сәламәтләндерү буенча чараларны вакытында күрү максатыннан, предприятиеләрнең һәм оешмаларның агымдагы җитештерү-хуҗалык эшчәнлеген, финанс-икътисади хәлен өйрәнү һәм бәяләү;
- предприятиеләрнең кризис торышы сәбәпләрен ачыклау;
- предприятие җитәкчесенең һөнәри компетентлык дәрәҗәсен бәяләү;
- җитештерү-хуҗалык һәм финанс эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында предприятие белән идарә итү системаларын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү;
- ведомство карамагындагы предприятиеләрне финанс яктан сәламәтләндерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү (мөлкәт комплекслары буларак үзгәртеп кору, хосусыйлаштыру, бетерү яисә сату) һ.б.

- предприятиеләрне финанс ягыннан сәламәтләндерү программаларын эшләү буенча карарлар кабул итү.

## 3. Эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышлары квартал саен, квартал саен бухгалтерлык хисабы төзелгәннән соң, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан үткәрелә һәм әгәр анда аның составының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала.

3.2. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык яисә ябык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Комиссия әгъзасы кабул ителгән карар белән килешмәсә, аның теләге белән беркетмәдә аерым фикер чагылдыра. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

3.3. Комиссия әгъзаларына чакырулар һәм предприятиеләр турында әзерләнгән документлар утырыш көненә кадәр 7 көн кала җибәрелә.

3.5. Комиссия карары белән беркетмәгә Комиссия рәисе һәм секретаре имза сала.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия үзенә йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

- муниципаль унитар предприятиеләрнең, оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлеге мәсьәләләре буенча хисапларын, шулай ук кирәк булганда предприятиене аудиторлык тикшерүе үткәргән аудиторлык оешмасы җитәкчесе хисабын тыңларга;

- муниципаль унитар предприятиеләрдәнкирәкле мәгълүматны һәм документларның күчермәләрен билгеләнгән тәртиптә алырга һәм соратып алырга .